# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы**

**КАРАР № 1**

**Урыссу ш. т. п.** "02" 03 2021 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 21.11. 2014 ел, №19 "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына (2015 елның 18 маендагы №8 номерлы, 2015 елның 9 октябрендәге №19, 2018 елның 29 октябрендәге № 29, 2019 елның 16 декабрендәге №22, 19.11.2020 елның 19 ноябрендәге №12 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 2 пунктындагы 14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, юллар, автомобиль юллары, скверлар, парклар, һәйкәлләр, су алу скважиналары, үләт базлары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары, торак пунктлар, спорт, гомуми файдаланудагы башка җирләр, иҗтимагый (дәүләт) идарәсе һәм тарихи-мәдәни эшчәнлек өчен җирләрдән даими (сроксыз) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешендә оешмалар.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә

махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга, һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга .

3.Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 1 өлешендәге 5 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезендә 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Урыссу шәһәр тибындагы**
**поселогы Башлыгы -**
**Урыссу шәһәр тибындагы**
**поселогы Советы Рәисе** **А.Ә. Шәфигуллин**